ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ ОКТЯБРЬ * 2019 * КАЗАН

10



Валентин ДРУЖИНИН

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

• Пуанкаре теоремасын исбатлаган математик Перельман, үзенең пенсиясен Пенсия фонды формуласы буенча чутлап чыгара алмаган.

• Ассошийэтед Пресс хәбәренчә, Урта диңгездә танкер урынына паром тулы Сирия качакларын тоткарлаган Сомали пиратларын коткару операциясе бара.

• Очыш уңышлы тәмамланганнан соң, робот Фёдор Роскосмосны җитәкләргә мөмкин.

• Телевидениеда тәүлек буе эшләүче "Украина турында" каналы барлыкка киләчәк.

• Пласидо Домингоның хәерче дәрәҗәсенә төшкән финанс хәле турында мәгълүматлар чыккач, җырчы тарафыннан көчләнгән хатын-кызларның дәгъвалары бермә-бер кимегән.

• Суд карары үзенең иренә "сарык" дип атарга рөхсәт биргән.

• Күмү йоласын үтәүче хезмәткәрләр тагын мәетне бүлешә алмаганнар.

• Хәрби космик көчләрдә дошман самолетларына һөҗүм итү өчен сугышчан акчарлак гаскәри частьлары булдырылган.

• Банкка килгән клиент, банк хезмәткәренең аннан бармак эзләрен калдыру үтенечена җавап йөзеннән, бармагы белән моның күзенә төрткән.

• Демографлар, әгәр илдә беркем дә үзен кол итеп тоймый башласа, илнең халкы ике мәртәбә артачак дип ышандыралар.

• Олылар өчен кибетләрдә кабартылган резина омончылары барлыкка килгән – алар белән рөхсәт ителмәгән секс ысуллары куллануга ирек бирелгән.

• Им-том һәм сихер салоны ачкан хуҗабикә салым инспекторларның, янгын сүндерүчеләрнең, санэпидемстанция хезмәткәрләренең һәм экологларының бөтен теләк-нәфесләрен бер карауда сизеп алган.

• Йорт җиһазлары фабрикасындагы шкафта скелет табылган.

• Ресторан кухнясында геннары модификацияләнгән яшелчәләр үзара сугыш оештырган.



ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Бөтен илгә шаулап узган бөтенебезгә дә таныш Собчак һәм моңа кадәр беркем дә белмәгән режиссёр Богомоловның туйлары күпләрне тетрәндерде. Кияү белән кәләшнең катафалкка утырып йөрүләре, каберлек төсләрендәге туй мәҗлесе, кәләшнең кунаклар алдында чишенүе – болар барысы да чирканудан башка тойгы уята алмый. Ә бу ханым бит күптән түгел генә президент булырга җыенган иде...

Д. ГАЗЫЙМОВА

ӘГЕРҖЕ

– Президент Собчак Россияне табутка салып катафалкта алып киткән булыр иде, – диде Шомбай ага, укучының хатын укып чыккач.

СОҢАРМЫЙЧА КИЛӘ...

Әллә нәрсә булды табигатькә –
Теләмичә ата таңнары,
Яз җилләре иренеп кенә исә,
Ашыкмыйча кайта казлары.

Һәм җәе дә сәрхуш ир шикелле,
Әллә кайда йөри адашып.
Күренә дә китә, йә көз белән
Урыннарын куя алмашып...

Язлар-җәйләр килсә, килмәсә дә,
Сабырлыгың җыеп түз генә.
Бездә хәзер, яман указ кебек,
Соңармыйча килә көз генә...

Ринат АБЗАЛОВ

Александр СЕРГЕЕВ



Анатолий НЫРОВ



– ЖКХ хезмәткәрләре монда ничек эләккән?



Күпме генә тукыма, һич барып җитми: кәеф-сафа корганнан соң руль артына утыручылар саны кимеми. ЮХИДИ беркетмәләре һәм төрле "перехват"ларның даими каһарманнары – ирләр һәм хатыннар, яшьләр һәм картлар, чиновниклар һәм депутатлар, бизнесменнар һәм эшсезләр, хәтта хакимият вәкилләре. Штрафлар арта, каты чаралар кулланыла, әмма берни дә үзгәрми – "салган" килеш машина йөртүчеләр – муеннан, ә тәгәрмәч астына эләгүчеләр саны тагын да күбрәк...

Казанның Чехов урамында «Кроссовер»да барган "салмыш" ханым зур тизлектә светофор астында торган "Гранта"ны чәки, ә аннары агачка килеп бәрелә. Гүзәл зат шундый дәрәҗәдә исерек була ки, хәтта машинасыннан үзе чыгарлык хәлдә дә булмый.

Чаллыда 42 яшьлек җиңел машина йөртүче көпә-көндез фонарь баганасына килеп бәрелә. Мондый нәрсә көтмәгән бичара багана киселгән күк, авып төшә. Әйтергә кирәк, күптән түгел Казанда беренче күп функцияле "акыллы" багана барлыкка килде. Аның акылсыз йөртүчеләрдән сакланырга акылы җитәрме – әлегә билгесез...

Шул ук калада кызмача ир 59/04 номерлы йортның ишегалдында газоннар буенча автосәяхәткә чыккан. Аңа бу гына аз тоела, күрәсең, ул бер-бер артлы газон читендә торган машиналарны чәкергә тотына. Бу "күңел ачу" нәтиҗәсендә 12 автомобиль зыян күрә.

Казанның Рәхимов урамында ЮХИДИ экипажының игътибарын зур тизлектә баручы "Шкода" җәлеп итә. Арендага алынган машинаны йөртүче инспекторлар белән качышлы уйнап карарга була, һәм башка автомобильләр арасында югалырга тырышып карый. Әмма бик тиз такси машинасына килеп бәрелә. Чөнки ул, беркетмәдә язылганча, "алкогольдән исерүнең ачык билгеләре" белән була...

Андыйлар арасында үз "рецидивист"лары да очрый. Чаллыда яшәүче А. "кәефләнгән" хәлдә инспекторларга дүрт тапкыр эләккән. Һәр очракта ул җәзага тартылган: мәҗбүри эшләрдән башлап, колония белән дәвам иткәннәр. Ләкин бу чара да тәэсир итмәгән: ярты ел утырып чыккач, тагын исерек килеш рульгә утырган. Хәзер аңа тагын сигез айга таныш урыннарына кайтырга туры киләчәк...

Бу хәлләр белән танышкач, ирексездән үзеңә сорау биреп куясың: безнең кешедә хәмер йотка괜нан соң барлыкка килүче тыелгысыз машина йөртү теләген берәр ничек җиңеп буламы икән? Күргәнебезчә, бернинди зур штрафлар һәм каты законнар да берни үзгәртә алмый. Йөртү хокукыннан мәхрүм итәргәме? Икенче көнне үк йә ялган таныклык белән, йә гомумән документсыз кудыртачаклар. Бәлки төрмәгә утыртып куяргадыр? Алай дисәң, алар болай да хәмер чөмерергә яратучылар белән тулган, һәм бу исерек йөртүчеләрне һич тә куркытмый. Ә бәлки, совет заманындагы кебек, эшләренә хәбәр итеп, җәмәгатьчелек алдында битләрен кызартыргадыр? Әйтергә кирәк, адым саен без ишарә ясарга иялән гән Көнбатышта мондый тәэсир ясау ысуллары әлегә кадәр кулланып килә. "Градус астында" эләккән автомобиль йөртүчеләрне правараларыннан мәхрүм итеп һәм зур штрафка тартып кына калмыйлар, өстәвенә, алкогольнең зыяны турында лекцияләр тыңларга мәҗбүр итәләр. Ә аның "кыланышлары" турындагы кәгазь рәсми рәвештә аның шәхси документларына теркәлә. Биографиядәге мондый кара тап белән карьера үсеше турында хыялланасы гына кала...

Шул ук вакытта законның кырыслыгы җәмгыятьнең бөтен катлауларына карата да кулланырга тиеш, әлбәттә. Исерек килеш рульгә утыргансың икән – син җинаятьче, һәм берничек тә энекәш, баҗай йә авылдаш түгел. Бу кагыйдә закон сагында торучыларның үзләрен дә читләтеп үтәргә тиеш түгел. Эләккәнсең икән – җавап тот! Бәлки, шул чакта "салмыш" килеш җилдерергә сөючеләрнең саны бераз кимер?

Рәдиф МОТЫЙГУЛЛИН



Виталий ПОДВИЦКИЙ



Николай ВОРОНЦОВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Владимир ТИХОНОВ



• • •

Әби ЖКХ чыгымнары өчен түли.

– Әбекәй, бу акчаларың Совет заманыннан калган, алар инде иске – хәзер кулланыштан алынганнар!

– Сезнең торбаларыгыз да совет заманыныкы, шулай ук яраксызлар!

• • •

Израильдә Робин Гуд барлыкка килгән. Ул байларның акчасын ала да ярлыларга процент белән өләшә икән.

• • •

Нигә шулхәтле югары белем алырга ашкыналар икән? Менә безнең оешмадагы 25 кешенең икесе генә институт бетергән – җыештыручы һәм йомышка йөрүче.

• • •

Кырым белән барысы да аңлашыла. Ә менә Мәскәү урысларга кайчан әйләнеп кайтыр икән?

• • •

Сез менә мондый әйтемгә игътибар иткәнегез бармы: "Илебездәге хәзерге катлаулы чорда..." дигән сүзләрне теләсә кайчан кулланырга була бит.

• • •

40–50 еллардан соң соцчелтәрләрдә инде якты дөньядан күптән киткән миллионланган кешеләрнең сәхифәләре калыр. Интернет-зират барлыкка килер. Оныклар шунда кереп, ничек яшәгәнебезне һәм безнең нинди надан, дивана икәнебезне белерләр.

• • •

Авыру психологка килгән:

– Беләсезме, доктор, мине берәү дә аңлый алмый!

– Гафу итегез, аңламадым, сезне нәрсә борчый?

• • •

Бер кап-кара шәһәрнең кап-кара урамында урнашкан кап-кара өйнең кап-кара фатирында кап-кара берәү сөйләнеп утыра:

– Бүтән беркайчан да картриджыма үзем буяу салмаячакмын!

• • •

Ире телефонны алмаганда хатынының башында куерган сюжеттан да катлаулырак әкәмәт бер генә порнофильмда да юктыр...

Валентин ДРУЖИНИН



СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

• Хатын-кыз мәхәббәтнең – мәгънәсен, ә ир кеше бәясен белә.

• Сәясәттә уңышка ирешергә теләгән кеше намусын тезгендә тотарга тиеш.

• Чын яңалыклар – начар яңалыклар.

• Тормышта ләззәт бирә торган ялгышларны гына эшләргә кирәк.

• Хатын-кыз булу бик авыр. Чөнки, асылда, аңа ир кешеләр белән эш итәргә туры килә.

• Акчадан мөһимрәк нәрсәләр дә бар, ләкин аларны акчасыз алып булмый.

Ринат АБЗАЛОВ





Наталья БАХТИНА


Кайнар су

Суны өч-дүрт көнгә өзеп торабыз дигәннәр иде, ә ул бер айга сузылды. Рәхәт тормышка бер ияләнгән кешегә авыр шул, шуңа күрә берәүләр мунчалы коттедж хуҗалары белән дуслашты, икенчеләре, коммуналь хезмәтне атасы-анасы белән сүгә-сүгә, кәстрүлләрдә су кайнатты. Һәм барысы да зарыгып бу газапларның бетүен көтте.

Ниһаять, җирле мәгълүмат чаралары тантаналы рәвештә ремонт эшләренең тәмам булуы турында хәбәр итте. Шәһәр җиңел сулап куйды. Фатирларда краннар, пошкыра-пошкыра, болганчык салкын су белән төкеренә башлады. Кагыйдә буенча, чиста су килә башлаганчы аны бераз агызып торырга кирәк иде, әлбәттә, ләкин бөтенесендә дә счётчик тора шул! Беркемнең дә башкалар өчен түләүле су агызасы килми. Икенче катта – икесе дә салым инспекциясендә эшли, акчалары күп – алар агызсын. Өченче каттагы яшь гаилә бер ел эчендә инде икенче иномаркасын алыштырды, алар ярдәмгә мохтаҗ түгел. Дүртенче катта – әнә, уллары инде ничәнче ел түләүле университетта укый. Калганнары да фәкыйрь түгел – ел саен Төркиягә баралар, хатыннары чәшке туннан йөри.

Бер атна үтте микән – бер әбекәй янына оныгы кунакка килеп төште. Ул әле тәҗрибәсез иде, һәм шул ук көнне йорттагы краннардан көмештәй саф кайнар су килә башлады.

Иван АНЧУКОВ





Виктор ФЁДОРОВ



ХӘМЕРДӘН – ТЕГЕ ДӨНЬЯГА

Татарстан тагын Россия буенча барысыннан да алда булып чыккан. Тик, кызганыч, бу – күңелсез беренчелек. Республикада алкогольле эчемлекләр куллану аркасында дөнья куючыларның саны 12 тапкыр арткан. Бездән башка, алдынгылар сафында Еврей автономияле өлкәсе – анда бу сан 6,7 һәм Тыва Республикасы – монда исә хәмердән үлүчеләр өч тапкырга арткан. Россия буенча тулаем алганда, спиртлы эчемлекләрдән һәлак булучыларның саны узган ел белән чагыштырганда 17,2 процентка арткан.

КҮМЕЛМӘС ГӨЛГӘ АЛАН...

Казан районара табигать саклау прокуратурасы республиканың Урман хуҗалыгы министрлыгы хезмәткәрләренең закон белән бик тату булмауларын ачыклаган. Мисал өчен, Олы Алан урман хуҗалыгы мәйданында урман кисү тыелган. Ә министрлыкта утыручы абзыйлар, моны белгән килеш, ике гектарда агач кисәргә рөхсәт биргәннәр. Ике йөз нараттан төпләре генә калган. Зыян 3 миллион сум тәшкил иткән, ә шома чиновникларга карата җинаять эше кузгатылган. Аларны урман кисәргә үк җибәрмәсләр, әлбәттә, ләкин җәзасыз да калдырмаячаклар.

ЗЫЯН КИТЕРҮЧЕ ДОКТОР

Яңа Чишмә район хастаханәсенең баш табибы Рафис Вафин берьюлы өч җинаять статьясына эләккән. Ул җитәкчелек иткән оешмада балигъ булмаган пациент кыз һәлак булган. Җитәкче, тикшерү эшләре тәмамлануын көтеп тормыйча, бу хәлне үз карамагына алырга булган. Кызның әти-әнисе янына барып, аларны куркыта башлаган. Имеш, гаризаларын кире алмасалар, алар медицина ярдәменнән мәхрүм калачаклар. Хәзер доктор, суд карары буенча өендә генә утырып, үзенә хөкем чыгарганны көтәчәк. Аны саксызлык, тикшерү эшләренә комачау итүдә һәм зыян күрүчеләргә басым ясауда гаеплиләр.

БАШКА МАКСАТЛАР

Азнакайдагы "Стәрле" фирмасы хезмәткәрләренә үзләренең намуслы рәвештә эшләнгән акчаларын прокуратура аша алырга туры килгән. Фирманың керемнәре җитәрлек булган, ләкин аның хуҗасы аларны башка максатлар өчен файдалануны артык күргән. Акча иң элек кредитларны капларга, электр өчен түләргә һәм башка хуҗалык ихтыяҗларына тотылган, ә егермеләп хезмәткәр ун ай буе хезмәт хакы алмыйча утырган. Бурыч 1,3 миллионга якынлашкан. Бу хәлдә акчасыз интегүче азнакайлылар прокуратура ярдәмгә килер дип өметләнәләр.



ЯРАКСЫЗ МӘЙДАНЧЫК

Хөрмәтле редакция! Элегрәк Фәрдиев исемендәге ял итү паркында балалар мәйданчыгы барлыкка килгән иде. Әкияти бинага охшатып ясалган шугалак, таган-карусель, заманча итеп эшләнгән кыяга үрмәләү дивары дисеңме – бар да бар, рәхәтлән генә. Яңа төзелгән мәйданчыкка сөенгән балаларны күрсәгез!.. Төзү белән генә эш бетми икән шул, балалар мәйданчыгын күзәткәләп торырга һәм күз-колак булырлык җаваплы кешесе дә булырга тиештер...

Баштарак пластик шугалак җимерелде, аннан карусель әйләнми башлады. Озак та үтмәде, башка җиһазлар да яраксызга чыкты. Әмма бераздан бу мәйданчык гүя сугыш кырына әверелде: ватык конструкциядән тимер-томырлар гына тырпаеп тора. Резина япкычлар ертылу сәбәпле, карусельдәге атлардан пружиналар селкенеп тора... Элеккеге матурлыкны сагынып сөйләргә генә калды. Хәзер моны балалар мәйданчыгы дип атарга тел дә әйләнми. Яшүсмерләр җыелып, сыра эчә, музыка акырта торган урынга әверелеп калды...

Дөрес, халыкның да гаебе аз түгел, булганның кадерен белмибез. Әлеге мәйданчыкны ачтылар да оныттылар: аның ни өчен кирәклеге кирәксез бер урынга әйләнеп калды сыман.

Ф. ЙОСЫПОВ

зәй

СӘЕР ИС

Кадерле "Чаян"! "Кытлык" сүзеннән котылып киләбез төсле иде, юк икән. Тулпар урамында яшәгән халык моны бик яхшы белә. Без тәүлек дәверендә саф һавага зур кытлык кичерәбез...

Өченче ел инде безнең микрорайонда канализация сасысы үзәккә үтә. "Җиденче күк" торак комплексын төзүгә үк әлеге сасы һава басып алды. Яңа мәктәп ачылуга ис тагын да көчәйде. Күкнең җиденче катына менсәң дә, әлеге бу хәләттән котылыр чара юк. Пластик тәрәзәләр дә коткармый. Өйләрне җилләтү турында сүз дә юк, урамга да бик чыкмаска тырышабыз.

Иснең каян чыкканын чакыртылган авария хезмәткәрләре дә белә алмый. Алар асфальтны ачып, актарып та карадылар, тик файдасыз. Дәүләт вәкилләре әйтүенә караганда, канализация юлы рәсмиләштерелгән кәгазьләр буенча ясалган һәм тоташтырылган. Ә безгә күпме түзәсе икәнлеге әлеге кәгазьләрдә әйтелмәгән микәнни?

А. ӘХМӘТҖАНОВА

казан

Александр ШУЛЬПИНОВ



– Әйе, бу поликлиника. Ә язуын баш табиб язды...


Илдар НӘФИЕВ



Валерий Тарасенко белән беренче сыйныфка







ТАТАР БАЛАСЫ

Беренче сентябрь – белем көне –
Казан урамнарыннан барам.
Татар гимназиясе янында
Түбәтәйле бала – күз салам.
«Татарча беләсеңме соң?» – диеп
Кызыксынып аннан сорадым.
Кыю гына «Знаю!» – дип салды
Укучы, җиңелчә кызарып...
Шундый җитез, төгәл җавап алгач,
Артык сораштырып тормадым,
Аптыраштан башым кашый-кашый,
Моңсу гына алга атладым...

Нияз БИШБАЛТА



• • •

Сакчының улы мәктәпкә өч тәүлеккә бер тапкыр йөргән.

• • •

Ата-аналарыгызны ихтирам итегез. Алар мәктәптә Гугл һәм Википедиядән башка укыган.

• • •

Улы әтисенә көндәлеген күрсәтә: математика – 2, физика – 2, биология – 2, тарих –2, җыр – 3. Әтисе – әнисенә: «Карале син, безнең мокыт әле җырлый да белә икән...»

"Саклый алмадык", – дип белдергән иде бервакыт Президентыбыз Владимир Путин Медведевның авырып китүе турында.

"Ә мин авырмадым", – дигән Премьер-министрыбыз кече бизнес вәкилләренә, берникадәр югалып торганнан соң.

Нинди генә чирләр юк кешедә,
"Ялган" чире шуның иң-иң хәтәре.
Андый зәхмәт эләктергәннәрнең
Сизми китеп бара бик-бик күпләре.
Ә бу китми, шулай яши бирә,
Гел-гел ялган аның бөтен белгәне.
Әллә авырган ул, бәлки, юктыр...
Ходай да бит алмый андый бәндәне.

"Симез мәчеләр", – дип "пешергән" иде Дмитрий Медведев спорт түрәләрен үзенең президентлык чорында.

"Бердәм Рәсәй" җыелышы –
Җыйган аны Илбашы.
Көн тәртибендә бер сүз –
Симез мәчеләр "башы".
Симергәннәр чамасыз нык –
Нәтиҗә юк спортта.
Гел үзләренә медальләр,
Спортчыга – ул юк та.
Үзәктә булырга тиеш –
Спортчы нәтиҗәсе!
Берәү дә белмәгән шуны,
Бу белгән – Беренчесе!

Дмитрий Медведев "Дорофей" исемле качкын мәчесе турында: "Борчылуыгыз өчен барыгызга да рәхмәт!" – дип белдергән.


Мәчесе качкан Илбашының.
Ташлап өен, хуҗасын
Кыен булды микән әллә соң
Күреп яшәү нужасын?..
Ул хәтле яшәмәгәндер лә
Безнең кебек интегеп?..
Кара, мәчесе дә качкан бит,
Чыдый алмый, яшь түгеп.
Мәче түзмәганне инде без
Ничек түзәргә тиеш?..
Акчасыз-нисез, ач-ялангач,
Күлмәк-ыштансыз килеш?..

"Бу минем соңгы соравым", – дип әйткән Обама Медведевка Сеулдагы очрашуда.

"Аңладым. Бу мәгълүматны Владимирга җиткерермен", – дигән Медведев.

Ах, бу микрофонны!.. Хыянәтче!
Ишеттергән барысын, сүндергәнче.
Чын президент түгеллекне белеп,
Көләрләр инде хәзер, үлгәнче!..

Алмаз ХӘМЗИННАН
шигырьләтә комментарийлар.



Илдар ӘХМӘДИЕВ, «Чаян» № 18, 1994

– Шәп качып яттың син бездән! Разведкада хезмәт итәрсең!



Эрнест ГЕЛЬМС, «Чаян» № 18, 1963

– Бөтен җирдә картлар, «дед»лар!..

Василий ШИМБЕРЕВ

Табигать хатасы

Трансгендерлар турында хәзер бөтенебез дә беләторгандыр. Әгәр кем дә булса белмичә калган икән – аңлатып бирәм. Бу кемдер булып туарга теләгән, ә бөтенләй башка кеше булып туган затлар. Табиблар хәзер бу мәсьәләне җиңел чишә – тиешле урында артыгы булса кисеп ташлый, ә җитмәсә – ябыштырып-тегеп куя. Мәсәлән, Камилә булгансың икән, хәзер син Камил. Рәхәтләнеп яшә!

Әгәр төптәнрәк карасак? Дөрес булып тумаганнар турында. Мисал өчен, кемдер әти-әнисе кебек сәхнәдә фонограммага җыр сузар өчен түгел, ә кирәк тотып җир казыр өчен туган булса? Бәлки алар нәкъ шул сәбәп белән эчкечелеккә сабышалардыр да? Юк, үземнең беркемнең дә башта җырлап, аннан соң канау казырга китүе турында ишеткәнем юк югын. Суд карары буенча булса гына...

Бәлки, табигать хатасын чынлап та суд төзәтергә тиештер? Әгәр кеше яраткан эшеннән башка иза чигә икән... Тикшереп карарга! Шунда ук хөкем залында, микрофонсыз, электроника-мазардан башка гына "Галиябану"ны сузып карасын! Булдырыр микән?

Ә җырчыбыз сүзләрен дә белми, бер нота да ала алмый икән – кулына көрәк һәм алга! Табигать хатасын төзәтергә!



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Интернетта язышу:

– Сезнең гәүдәгезнең төзелеше нинди рәк?

– Спортчыларныкы кебек.

– Ә нинди спорт белән шөгыльләнәсез?

– Сумо белән.

• • •

Хатын-кызлардан аермалы буларак, ирләр бүленешеп үрчиләр. Акчаңны хатын-кыз белән бүлешмисең икән – үрчемисең.

• • •

Кайбер замандашларыбызның китабын укыгач, башка шундый уй килә: "Интернетка яздыр – урманны сакла".

• • •

– Доктор, сезнең авыру нәрсәдән үлеп китте?

– Картлыктан.

– Ләкин ул машинага тапталып үлде бит?

– Яшьрәк булган булса – сикереп чыгып өлгергән булыр иде.

• • •

Караңгы төндә шкафтан кинәт ниндидер тавыш ишетелде. Ачып җибәрүем булды, аннан хатынымның киемнәре модадан чыгып бара.

• • •

– Әни, әбиләр корсакта чакта ук әби булганмы?

– Әйе.

– Ә син әбинекендә?

– Әйе.

– Ә синдә – мин?

– Әйе.

– Ә без нәрсә, матрёшкалармы?

• • •

Хәзерге заман сәнгать музеенда йөргәндә күңелем шатлана: ә бит мин балачакта шәп кенә рәсемнәр ясаганмын икән!

• • •

Егет кыз артыннан йөгерә:

– Туташ, туташ...

– Нәрсә?

– Сез автобуста сумкагызны онытып калдырмадыгызмы?

– Әйе шул, оныткнмын!

– Алайса, йөгерегез автобус артыннан, ул әле ерак китмәгәндер.



Абау!

ТАНТАНАЛЫ АЧУ

Тверьда кешеләрнең бозыклыклары белән изге су ярдәмендә көрәшә башлаганнар. Дин әһелләре самолетка утырып, шәһәр өстендә әйләнгәннәр, анда яшәүчеләрне эчкечелектән һәм фахишәләрдән азат итәр өчен 70 литр изге су түккәннәр. Бу тәреле очуда үз нечкәлекләре дә бар. Дин әһелләре аңлатуынча, суны нәкъ менә түгәргә туры килгән, чөнки сипкән су тамчылары кире самолетка керә икән. Бу эш 2006 елдан бирле башкарыла. Шәһәрдә яшәүчеләрне бу вакыт эчендә наркотиклардан, эчкечелектән һәм башка бәлаказадан арындырганнар. Тик бу алымның нәтиҗәлелеге турында төгәл дәлилләр юк.

ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ ЫСУЛЫ

Чиләбе өлкәсенең Златоуст шәһәренең түрәләре арзанга гына шәһәрне яшелләндерергә һәм бер уңайдан житешсезлекләрен яшерергә исәп иткәннәр. Шәһәрнең трассаларын рәтләгәнәр, юл кырыендагы яңгыр суы ага торган канализация чокырларын бизәгәннәр. Канаулар өстенә бетон плиталәр салганнар һәм өстенә яшел ковролин җәйгәннәр. Экспресс-газонны губернатор Алексей Текслер килүенә җәелгән була. Аның Златоустка беренче килеше була.

ФИЛЬКИНО КҮПЕРЕ

Свердловск өлкәсенең Филькино поселогында Кавка елгасы аша ачылган күпер бары тик бер көн торган. Халык бу күперне ике ел көткән, хәтта үз көчләре белән берничә тапкыр вакытлыча күпердә ясап караган булганнар. Ниһаять, администрация бу проблеманы чишәргә алынган һәм понтон күпере төзегәннәр. Тик тантаналы ачылуга йөзеп баручы бүрәнә комачаулаган. Ул күперне генә җимереп калмаган, җирле администрациягә зыян китергән – хакимияткә карата ваемсызлык буенча эш ачканнар.

КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ КОРАЛ БЕЛӘН

Филиппин президенты Родриго Дутерте гражданнарга коррупционер-түрәләргә атарга рөхсәт биргән. "Сез салым түлисез икән, шуның өстенә түрәләр сездән ришвәт сорый икән, сугыгыз аларга. Коралыгыз булса, атарга да мөмкин", – дип әйткән дәүләт җитәкчесе. Тик Дутерте әзрәк ялгышкан, ришвәт алучыларны үтерергә ярамый, утыртып куярга мөмкиннәр. Ә коррупционерга аткан кешегә физик җәза гына бирелә.



Николай ВОРОНЦОВ



Александр КОСМЫЛИН



Анастасия ВАСИЛЬЕВА

– Ә таҗыңны карчык киеп карасын әле!

Хакимият

Александр БРЮХАНОВ

Башта шәһәребездә һәркем үзе теләгәнчә яши иде...

Ләкин тормыш гел син дигәнчә генә бармый шул. Берзаман шәһәрдә башлык сайларга булдылар һәм ирекле сайлаулар игълан иттеләр.

Хакимияткә буш сүз сөйләүче такылдыклар килде. Алар бертукаусыз татлы сүзләр сөйләп, вәгъдәләр өләште. Аларга, әлбәттә, ышандылар, тик ышану кими башлау белән аларның урынын башка такылдыклар ала торды һәм бөтенесе шулай ук дәвам итте.

Ә халык бу вакытта бик авыр яши иде. Ә кайберәүләр, гомумән, яшәми – чөнки яшәр урыннары юк иде... һәм шул чакта хакимияткә төзүчеләр килде, һәм бөтен шәһәр буенча йортлар төзи башлады. Иске йортларны җимерү, агачларны кисү, елгаларны күмү китте һәм төзү, төзү, төзү... Халыкның акчасы бетеп, йортлар сатып алынмый башлагач кына туктадылар...


Болардан соң банкирлар хакимлек итә башлады. Халык мул яшәсен өчен ниләр генә уйлап чыгармады алар – кредитлар дисеңме, төрле бонуслар, пирамидалар дисеңме... Ләкин мул, бай тормыш беркемгә дә тәтемәде, банкирларның үзләреннән һәм туган-тумачаларыннан башка, әлбәттә. Халык тагын тынгысызлана башлады...

Банкирларны табиблар белән бергәләшеп аптека хуҗалары алыштырды. Шәһәрне барча чирләрне дәвалаучы табиблар, гомерне озынайту рецептлары язып йөрүчеләр тутырды. Хастаханәләрдә озын-озын чиратлар, аптекаларда мең-меңләгән дарулар барлыкка килде. Халык дару алырга ябырылды...

Менә шул чакта ритуаль хезмәттә эшләүчеләр баш күтәрде. Һәркемгә ташламалар белән затлы җирләү, һәм барчасына да теге дөньяда яхшы тормыш вәгъдә иттеләр.

Тик халыкка тагын нәрсәдер ошамады. Хәзер инде беркем дә кемне сайларга икәнен белми иде.

Шунда көтмәгәндә хакимлеккә психиатрлар килде, һәм шәһәр җүләрләр йортына әверелде. Һәркем җаны нәрсә тели, шуны эшли башлады. Тик озакка микән? Анысын вакыт күрсәтер...



Александр КОСМЫЛИН



Евгений ОБУХОВ

Күрсәтер идем...

Әгар да мин Абрамович йә Дерипаска кебек миллиардер булсам, күрсәтер идем чынлап яшәүнең нәрсә икәнен! Беренче эш итеп иске "шестёркамның" тизлек коробкасын алыштырыр идем. Балыкка йөргәндә интекмәскә. Һәм кармакның импортныен, карбоннан ясалганын сатып алыр идем! Кортны да өй артында казып чиләнмәс идем – банкасын кырык сумнан кибеттә әзерен генә алыр идем...

Тагын нәрсә? Дача. Яңаны алыр идем, әлбәттә. Кайнатайдан калган, шәһәрдән йөз чакрымда урнашкан дачаны сатар идем. Һәм якынрагын алыр идем, бер сәгатьтә барып җитәрлеген (һәрхәлдә, "бөке"ләр булганда да биш сәгатьтән артыграк булмасын иде). Җире дә күбрәк булсын – алты сутый түгел, ә ун. Вакланып тормаска да була: булгач-булгач унике итәргә дә ярый. Миллиардер кеше иркен яшәргә тиеш бит ул!


Тешләр турында онытмаска! Бу череп беткән ике урт тешне алыштырыр идем. Алга – яңа пломба. Бөтен җирдә дә беренче рәттә генә утырыр идем: концертта да, хәтта кинода да. Ә поездда купеда гына кайтыр идем, кәнишне, кайтканда бүләкләр тулы чемоданнарга урын кирәк бит! Ә барганда плацкартта да ярый – буш чемоданнарны эскәмия астына да куярга була ич...

Киемнән – үземә яңа куртка алыр идем, һәм, ниһаять, ертык резин итекне ябыштыртыр идем – гел балыкка йә гөмбәгә йөрергә туры килә бит. Күршенеке кебек зур диагональле яссы телевизор алыр идем. Күрсен әле күршеләр миллиардерларның ничек яшәгәнен...

Алай дисәң, икенче яктан, ул миллиардлар белән күпме мәшәкать... Курс төшү, дефолт, индекслар.. Өстәвенә, конкуренция, сәясәт, санкцияләр... Төрмәгә эләгүең дә бар... Тфу! Ярый, телевизор күрсәтә әле, карарга була. Курткасы да аллә ни иске түгел – өч-дүрт ел йөрергә була әле. Итекне дә үзем ябыштыра алам, ярарлык ямау таптым инде. Зарплата көнне "Момент" келәе алам да...

Әле хезмәт хакын йөз сумга арттырдылар. Келәйгә җитәчәк!

Виктор ФЁДОРОВ



БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Европада совет сугышчысына куелган һәйкәлне җимерәләр – Россия берни эшли алмый. Зу-ур илдә туган телебез нигезләрен какшаталар – без дә берни кыла алмыйбыз түгелме?

Алмаз Хәмзин: Без мондый очракта бары тик дога гына кыла алабыз – "Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!"

Р. Н.: Моннан 4-5 ел элек: Россиядә милли идея булмау – үзе бер идея", – дип язган идем. Ә хәзер менә, ниһаять, табылды: ул – патриотизм икән...

А. Х.: Патриотизм түгел ул – бандитизм!

Р. Н.: Без ялган океанда яшибез – дөньядагы мәгълүматның алтмыш проценты ялганнан тора...

А. Х.: Ә калган 40% ы алдаудан.

Р. Н.: Әҗәлетдиннең эше муеннан: ул гади кешене дә, президентларны да аяп тормый...

А. Х.: Әле аңа хөкүмәт булыша!..

Р. Н.: Әй, сез, олигархлар! Акчага табынмагыз – теге дөньяда аның өч тиенгә дә кирәге юк...

А. Х.: Сине ишеттеләр дә, ди, сүзләреңне игътибарга алдылар, ди. Һәм утырып еладылар, ди.

Р. Н.: Яңа заман байлары "Мин – хәерче" дип язу калдырудан да чирканмас.

А. Х.: Алар үз үлемнәре белән үлмиләр бит, какуй язу калдыру...

Р. Н.: Хатыныңнан уңмасаң – йә ахмак, йә философ булуыңны көт тә тор!

А. Х.: Күптән шулай диләр аны – нишләргә белми башлагач, йә Россиягә бәйләнәсең, йә байларга, олигархларга...





Алексей МАМАЕВ



– Ә бу безнең граната атучылар!

Александр АЛЁШИН



Алмаз ХӘМЗИН сүзләре

МҮКЛЕ БӘЙРӘМНӘР

(замана такмаклары)

Шашты дөнья чамасызга –
Көн дә бәйрәм дә, бәйрәм.
Элек елга биш көн иде,
Хәзер биш йөзләп бәйрәм.

Ә нигә шулай, дисезме?
Фантазер бит кешеләр...
Һәркемнең туган көне бар,
Хәтта елга икешәр.

Бала тугач, көн дә бәйрәм –
Үчтеки дә үчтеки...
Аннан юбилее җитә –
Бер яшь тула чүтеки.

Ә нигә шулай, дисезме?
Модага кергән гадәт:
Бүләккә телефон яки
Сөйләшә торган сәгать.

Кайберәүләр үткәрәләр
Мәчеләренең туен.
Кода-кодагый булалар,
Юк, юк, түгел бу уен.

Ә нигә шулай, дисезме?
Кыланчык бит кешеләр:
– Алар да гаилә әгъзасы, –
Диләр, – безнең ишеләр.

Эт туйлары да уздыру
Бик кызыклы күренеш.
Күрсәң, ул хуҗаларының
Сөенүләрен – үлеш.

Ә нигә шулай, дисезме?
Акчасы күп кешеләр,
Чыдый алмыйча маена,
Эт хәленә төшәләр.

Кайберәүләр ик(е)шәр туа,
Дигән идем баштарак.
Атылгач, исән калган ул –
Бандит булган, йә карак.

Ә нигә шулай, дисезме?
Хәрам малга ия күп.
Басты, дуслар, чарасызлык
Йөрәкне каплады мүк.

1 ноябрьда Рафгать РЫСАЕВка 80 яшь тула.

Журналыбызның даими авторы – Башкортстанның Стәрлебаш районы Тәтер-Арслан авылында яшәп иҗат итүче Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рәфгатьне күркәм бәйрәме белән котлап, өч шигырен тәкъдим итәбез.

ЯШЬЛЕК МӘХӘББӘТЕМ

Үткәннәрем кичәгемдә калды,
Бүгенгемне беләм, алдымда.
Иртәгәмнең алчак йөзен күрәм,
Күңел тарткан шигъри табында.
Шигъри сүзгә халык фикеренең
Энҗе-мәрҗәннәре җыелган.
Ул үлемсез! Милләт тарафыннан
Гомерен чикләү катгый тыелган.
Чал башымны иеп китеп барам,
Якыная инде зур ара.
Шигърият ул яшьлек мәхәббәтем
Картайгач та сөйми юк чара.

КИРЕ КАЙТА

Бер өйдә икәүләр: ир һәм хатын,
Хатын рәнҗи-рәнҗи ялына.
Соңгы тамчы горурлыгын җуеп,
Алла урынына табына.
Ир торганы – һавадагы бөркет,
Аның караш шундый югары.
Хатын бахыр, хатын өтәләгән
Йолкыш чебеш гүя нибары.
Шушы ук өй, шул ук икәү, ләкин
Заман башка, дөнья үзгәргән.
Теге батыр тынып, сүнеп калган,
Очкын очмый тоныкл күзләрдән.
Аягында атлап йөри алмый,
Киң сулышы алып бетелгән.
Хатынына багып, түшәгендә
Ятарга дип хөкем ителгән.
Бер халәт тә мәңгелек түгел шул,
Иртән чыккан кояш кич бата.
Адәм кылган барча яхшылык та,
Начарлык та кире бер кайта.

АВЫЛЫМНЫҢ КЫЗЫЛ МӘЙДАНЫ

Яшәештә даны булмаса да,
Ихтирамга лаек иҗаты.
Берәмтекләп куенына җыя
Балаларын авыл зираты.
Дәрәҗәләр аңа бар ни, юк ни,
Эшчән, ялкау – бар да бер чама.
Исән чакта кайта алмаганнар,
Үлгәч, күкрәгенә баш сала.
Кемнәр йөрәгендә мәхәббәтнең
Туган җиргә йөртә зурысын.
Шулар кайта түләп бетерергә
Түләп бетермәгән бурычын.
Һәммәсенә капкасы шар ачык,
Кем килсә дә урын җитәрлек.
Биредәге тынлык! Ызгыш-талаш
Юклыгына исең китәрлек.
Җеназа һәм бәйрәм көннәрендә
Бөтен халык монда агыла.
Һәр кешегә кердән арынырга
Сафландыргыч дулкын кагыла.
Яшәештә данга лаексыз дип,
Нык төшердем бугай чын хакын,
Авылымның Кызыл мәйданы ул,
Авылдашлар яткан зиратым.



Алмаз ХӘМЗИН

ЯМЕ?!

Күрдем сине,
Туган авылыңны,
Исәнме соң бәгырь кисәгең?..
Алай икән...
80 тулды дисең:
Гел бергә атлагыз,
һәрбер көнен
Туксанынчы дистәңнең.
Кояш көләр
Әле синең өчен!
Шагыйрьләрне нәрсә яшәртә?!

Зират түгел,
Яме, сагышланма!
Әйләнеп үт читтән
Кайгы коймасын!
Гел уфтанып ятма түшәктә!
80 әле,
80 генә бит ул:
Яшәешнең ахыры күп аның!..
Сиңа теләк:
Йөзләргәчә җиткәч,
Безне шатландырып
Чыксын иде, их!
Бергә укыр саллы китабың!







Бер ай элек Өммикамалның утызны узып баручы кече оныгы үзеннән биш яшькә кече бер авыл малаена кияүгә чыкты. Ә туй буласы көн дүрт-биш ай элек үк мәгълүм булган иде. Бу хәбәрне аңа килене җиткерде. Ә бер көнне ул Өммикамалны аяктан егарлык сорау биреп куйды:

– Әни, "хрущевка"дагы бер бүлмәле фатирыңны балаларга бүләк итеп биреп булмасмы икән? Кияү буласы егетнең дә шәһәрдә торыр урыны юк ди...

Үзе җавап көтеп тормый гына өйдәге вак-төяк эш белән мәшгуль булды.

Өммикамал карчык исә бик авыр кабул итте бу тәкъдимне. Ул ашаудан калды, күзенә йокы кермәс булды. Ул ни дип җавап бирергә дә белмәде. Кире үз өенә кайтып китү турында да уйланып алды... Ә туй көннәре аның күңеленә кара күләгә төшерә барып, һаман якынлаша иде...

Әнә шулай, үз-үзен эчтән битәрләп яткан көннәрнең берсендә булачак кияү белән онысы кайтып кермәсенме. Кулларында чәчәк, торт. Йөзләрендә нур, ихласлылык, эчкерсезлек. Булачак парларның яшьлек хисләре дә ярларыннан ташып чыгып, йөрешләренә, күз карашларына, телләренә кучкәнлеге сизелеп тора. Килеп керү белән үк онысы:

– Әбекәй, бу Алмаз, ишеткәнсеңдер инде...

– Ничек ишетмәсен инде, нурлы күз карашларына чаклы минем дәү әнигә ошаган ич ул, — дип, Алмаз аның янына барып утырды.

– Әбекәй, бу матур онысыңны миңа бирерсез микән, — дип, балаларчарак итеп, уены-чыны белән сорап куйды ул.

– Мена, кызым ни дияр бит, ул әйткәнчә булыр, — диде Өммикамал.

Яшьләрнең күз карашлары очрашып алды, ирен читләренә җиңелчә елмаю чыкты. Аннары әбинең онысы:

– Мин чәй куям, бераздан торт белән чәй эчеп алырбыз дип, кухня ягына чыгып китте.

...Туйлар гөрләп үтте. Яшь парларны котлап конверт-конверт акчалар янына конверт-фатир да өстәлде. Яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтару кирәклеген кияү кеше дә бик яхшы аңлады, һәм ул Өммикамал карчыкка көтелмәгән тәкъдим ясап, аның аһ-ваена карамастан, үзләре белән туй сәяхәтенә, Төркиягә алып китте...

Өммикамал карчык бу турыда бәйнә-бәйнә итеп күршедә яшәүче ахирәтләренә сөйләде.

– ...Оланнар башта мине диңгез буенда ял итүчеләр сыман итеп киендерделәр. Шорты, бернича коену костюмы алдылар. Киң кырлы эшләпә, кара күзлек тә киеп җибәргәч...

– Әстәгъфирулла! Әстәгъфирулла! – диешеп куйдылар ахирәтләре.

– Ул диңгезнең матурлыгы, чисталыгы. Суының җылылыгы, дулкыннар кочагында йөзүнең рәхәтлеге...

Аннары, кабаланып, төрек мунчасы турында сөйләргә кереште.

– Кияү "хамам" дигән җирдә ун тапкыр массаж алырга кушты, акчасын да үзе түләде. И-и андагы рәхәтлек, бер якта ир-атлар, икенче якта – без. Кайнар ташка аркаң белән ятасың...

– Әбиләрнең шар булып ачылган күзләре берара йомылмас булды, алар, сорау бирүдән куркып, хәтта авызларын да яулык чите белән каплап ук утыра башладылар.

– Әйе. Шундый чибәр, яшь төрек егетләре башта өстеңә бер капчык тәмле исле сабын күбеге коя, аннары махсус бияләй киеп шул күбек астына кереп китә. Әрсез, йомшак бияләйле кулларның кайларда йөргәнлеген синнән башка берәү дә белми... Алга таба үзеңне генә икенче бүлмәгә алып кереп китәләр. Аннары зәйтүн мае белән муен сөягеннән башлап аяк табаннарыңа чаклы ышкып чыгалар. Оҗмах инде...

– Онытып торам икән, иртәнге якта мин аэробикага да йөрдем бит әле. Яшьләрдән бик калышмавыма үзем дә сөендем.

Өммикамал, сүзен гамәл белән дәлилләп күрсәтәсе килепме, урыныннан кузгалып, бер-ике адым читкә китте, аннары бераз гына итәген күтәргәндә итте дә, шалт итеп шпагатка утырды.

Ул берни булмагандай торып басты, итәген каккалап алды, аннары тагын нидер сөйләргә дип авызын ачкан гына иде, үзләренә таба килеп баручы киявен күреп, тукталып калды.

– Исәнмесез, апалар! Исәнме, әби!

– Әби, мин балет театрына билетлар алган идем, берәр сәгатьтән килеп җитәбез, әзерләнә тор. Төркиядән алган теге күлмәгеңне киярга онытма, – диде дә артык сүз катып тормыйча китеп тә барды.

– Ярар, кызлар, алайса иртәгә кадәр, – дип, карчык өенә кереп китте.

Әбиләр, берара дәшми-нитми генә Өммикамалның тирбәлебрәк атлаган гәүдәсенә бераз сокланып, бераз көнләшеп дигәндәй, карап тордылар да:

– Спекулят спекулянт инде, дигән нәтиҗә ясадылар. – Совет заманында шул иде, хәзер дә шул.

...Ә инде торак мәсьәләсенә килгәндә, яшьләр әбинең "хрущевка"сына күченмәделәр. Киресенчә, алар ел ярым эчендә "Салават күпере" микрорайоныннан өч бүлмәле фатир сатып алдылар.

Мидхәт САДЫЙКОВ.



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 10 (1888) сентябрь 2019

Баш редактор
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
А. АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Җаваплы секретарь: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН, Л. ӘХМӘТОВА, Г. СӨНГАТУЛЛИНА,
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йа https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 30.09.2019 ел.
Тираж – 1105 Заказ О-2669

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Биш фигыльдән бер җөмлә?

2. Суганнан, йомыркадан, ләкин пирожки түгел?

3. Ни өчен җәя һәм ук белән ауга йөрергә рөхсәт иткәннәр?

4. Табибка нигә йөриләр?

5. Түләүле һәм түләүсез медицинаның аермасы нидә?

6. Ни өчен болай әйтелә: әгәр синең бер яңагыңа кундырсалар, икенчесен дә куй?

7. Яхшы ир кем ул?

ҖАВАПЛАР

1. Әчәргә алырга барырга торырга уйладым. 2. Робин Гуд. 3. Дүртенче дөнья сугышына әзерләнәләр. 4. Нинди авыру белән авырганын белү һәм аннан соң ул турыда интернеттан уку өчен. 5. Түләүсез медицина соңгы сулышка хәтле дәвалый, ә түләүлесе – соңгы тиенеңә хәтле. 6. Яңак үз урынына утырсын өчен. 7. Космонавт. Хезмәт хакы зур, ярты еллап – командировкада, кайткач, бөтен ил белә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исеме укыгыз. Журналыбызның 9 нчы санында басылган чайнвордның тикшеру сүзе — **«МИНЕМ КАДЕРЛЕЛӘРЕМ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Ульяновск),
Л. ГӘРӘЕВА (Сарман р-ны, Җәлил бистәсе),
С. ЗАРИПОВ (Сарман р-ны, Юлтимер ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез –
Урманасты Шонталасыннан
Диләә НУРГАТИНА!

КӨЗГЕ АЧЫ ҖИЛЛӘРДӘ...

